РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕМОРБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Советская ул., дом 47,
с. Шеморбаш, 422667

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШОМЫРБАШ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 47 нчы йорт,
Шомырбаш авылы, 422667

Тел.: (8-4361) 20-415, факс: (8-4361) 20-415, эл.адрес: Smrb.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 12.07.2017 ел Шомырбаш ав. № 16

Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ
җәза бирелә торган оешмалар исемлеген
һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында

1. Суд карарының законлы көченә кергән карары буенча административ җәза үтәү рәвешендә башкарылучы мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри булып саналуын исәпкә алып, №1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге территориясендә административ җәза үтәтү өчен мәҗбүри эш төрләрен билгеләү мәҗбүри эш дип санала.

2. Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларның китү урыннарын булып - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре санала.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген № 2 кушымта нигезендә расларга.

4. Мәҗбүри эшләрне күрсәтелгән административ җәза билгеләнгән затларның яшәү урыны буенча башкарырга кирәк.

5. Административ җәза билгеләнгән затлар мәҗбүри эшләр башкара торган оешма җитәкчеләренә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында һәм хезмәт законнарында каралган вазыйфалар йөкләнә дип билгеләргә.

6. Суд приставларының федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Балык Бистәсе район бүлегенә административ җәза билгеләнгән затлар мәҗбүри эшләр башкара торган оешмалар администрацияләренә хокукый һәм методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәүче оешмалар исемлеген һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында»2014 ел, 20 гыйнвар, 2 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

8.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

9. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгы И.Н.Сафин

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы  Шомырбаш авыл җирлеге башкарма комитеты 2017 елның 12 июле, № 16  карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге территориясендә административ җәза үтәтү өчен мәҗбүри эш төрләре**

1. Тышкы төзекләндерү объектларын яшелләндерү, агымдагы карап тоту һәм үстерү буенча эшләр.

2. Урамнарны җыештыру.

3. Лесосекларга бүлеп бирү (визалар кисү, делянка баганалары ясау һәм урнаштыру).

4. Урман фонды территорияләрен төзекләндерү (урман кишәрлекләрен рөхсәтсез җитештерү һәм куллану калдыкларыннан чистарту, ял итү урыннарын, беседкаларны урнаштыру).

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге башкарма комитеты 2017 елның 12 июле, № 16 карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге башкарма комитеты.

2. «Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча).

3. «Кама урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча).